**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә йогышлылыгы югары булган кош гриппы белән чирләү һәм аның таралу куркынычы янау белән бәйле рәвештә, аларның иминлексезлеге сәбәпле чикләү чараларын (карантинны) бетерү турында

Кошларның йогышлылыгы югары булган кош гриппы белән чирләвен бетерү һәм булдырмау буенча эпизоотиягә каршы һәм профилактик чаралар үтәлүе белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законының $3^1$ статьясы, Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының 2006 елның 27 мартындагы 90 номерлы карары нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасының түбәндәге аерым территорияләрендә йогышлылыгы югары булган кош гриппы белән чирләү нәтиҗәсендә иминсезлекләре һәм аның таралу куркынычы белән бәйле рәвештә кертелгән чикләү чараларын (карантинны) бетерергә:

Нурлат шәһәренең Түбән Нурлат урамындагы 45, 86 номерлы йортларның шәхси хуҗалыклары;

Нурлат шәһәрендә «Хәмидуллин З.З.» крестьян (фермер) хуҗалыгы тарафыннан кош-корт асрау өчен кулланыла торган ферма территориясенең бер өлеше;

«Хәмидуллин З.З.» крестьян (фермер) хуҗалыгы тарафыннан кош-корт асрау өчен кулланыла торган ферма территориясенең Нурлат районы Чуаш Мәнҗесе авылы янындагы бер өлеше;

Балык Бистәсе районының Шумково авылының Үзәк урамындагы 18 номерлы йортның шәхси хуҗалыгы;

Ютазы районы Әбсәләм авылының Луговая урамындагы 1 номерлы йортның шәхси хуҗалыгы;

Казан шәһәре Дербышки торак массивының 3 нче Кленовая урамындагы 90 номерлы йортның шәхси хуҗалыгы.

2. Әлеге Указның 1 пунктында күрсәтелгән территорияләрдә өч ай дәвамында барлык кош-корт асраучыларга башка хуҗалыкларга яралгылы йомырка һәм барлык төрдәге тере кош-корт чыгаруны чикләргә.

3. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә йогышлылыгы югары булган кош гриппы белән чирләү һәм аның таралу куркынычы янау белән бәйле рәвештә, аның иминлексезлеге сәбәпле чикләү чаралары (карантин) кертү турында» 2017 елның 16 маендагы ПУ-394 номерлы Указын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан,Кремль
2017 ел, 06 июнь
№ ПУ-470